ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«18 » май 2022 ел №65-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын тормышка ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлау комиссиясе составын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында»2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлау тәртибе буенча рекомендацияләр турында» Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 8 августындагы 08-1063 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлауның бердәм тәртибен билгеләү һәм үтәү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын тормышка ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлау комиссиясе составын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлау тәртибе буенча рекомендацияләр турында» 2013 елның 8 августындагы 08-1063 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына керү турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә, мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлауны оештырырга.

3. Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлау буенча комиссиягә мәктәпкәчә

белем бирү учреждениеләрен комплектлау буенча эшне һәр елның 1 июненнән 31 августына кадәр дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлау комиссиясе составын раслау турында» 2011 елның 8 июнендәге 94-р номерлы күрсәтмәсен үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге күрсәтмәне "Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://agryz.tatarstan.ru.

6. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
18.05.2022 № 65-р
күрсәтмәсе белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын тормышка ашыручы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлау комиссиясе составы**

1. Шәрипов Рөстәм Рәшит улы-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе;
2. Сафиуллина Вәсилә Гарәфетдин кызы - "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе начальнигы, комиссия рәисе урынбасары;

**Комиссия әгъзалары:**

3. Әхтәмова Гүзәлия Фәрит кызы - "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесенең мәгълүмати-методик бүлеге башлыгы;
4. Кәлимуллина Ләйсән Рамил кызы - "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе методисты;
5. Зиновьева Ландыш Илфар кызы - "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесенең баш белгече;
6. Шурманова Гөлнара Ринат кызы-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 1 нче номерлы "Алтын ачкыч" балалар бакчасы мөдире;
7. Яппарова Лилия Дуфар кызы-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 7 нче номерлы "Бәләкәч" балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире.